# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Бима авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Мадык торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

8 декабрь 2025 ел № 1

Гамәлдәге законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 8 декабрендә 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены буенча беркетмә төзелде.

Җыенда каралган сораулар:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Бима авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Мадык торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 31.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга ризамы? «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 28 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 кеше, бу 71% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 20 катнашучы тавыш бирде;

Җыенда «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

2.“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мадык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары ,

ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан), I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына вакытлы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә һәм ул акчаларны җирлек өчен әһәмиятле эшләргә түбәндәге эшләргә юнәлтергә ризамы?

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар сатып алу һәм алмаштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча түләү һәм урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

3. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (торак пунктта су белән тәэмин итү өчен сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү ( газон һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, трактор тоту һәм аны карап тоту, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү, балалар өчен уен мәйданчыгы өчен материаллар сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 28 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 кеше, бу 71% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 20 катнашучы тавыш бирде;

Җыенда «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы "Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мадык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мадык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары , ире яки хатыны, балиг булган балалары), I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарны көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына вакытлы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.
3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1). Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

2). Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар сатып алу һәм алмаштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча түләү һәм урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

3). Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (торак пунктта су белән тәэмин итү өчен сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар, су агызу өчен тимер торба сатып алу);
4). Торак пункт территориясен төзекләндерү (газон һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, трактор тоту һәм аны карап тоту, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү, балалар өчен уен мәйданчыгы өчен материаллар сатып алу).

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Бима авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Мадык торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 31.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга. «Россия Федерациясендә

җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче
муниципаль берәмлек башлыгы Э.И. Михайлов